ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е                    К А Р А Р

«11» гыйнвар 2019 ел                    № 7/1

2019 елга «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең план күрсәткечләрен һәм максатчан тотарга тиешле әлеге керемнәрдән хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджет учреждениеләре күрсәткән түләүле хезмәтләр өлкәсен үстерү максатында, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләменең планлы күрсәткечләрен һәм әлеге керемнәрдән хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен, кушымта нигезендә максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, билгеләргә.

2. «Финанс-бюджет палатасы» МКУ (Р.Х. Хәмидуллин) ай саен 10 числога кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына түләүле хезмәтләр күрсәтү төрләре буенча муниципаль учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән килә торган средстволар турында мәгълүмат тапшырырга һәм 20 числога кадәр муниципаль учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән кергән һәм тотылган средстволарны анализларга.

3.Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә кергән дип билгеләргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Финанс-бюджет палатасы» МКУ нә (Р.Х. Хәмидуллин) йөкләргә.

Җитәкче Н.Р. Залаков

Р.Х. Хәмидуллин
5-18-25